# КАРАР
## Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Иске Казиле авыл җирлеге Иске Казиле авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

1 нче декабрь 2025 ел № 8

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 45,69 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Кама Тамагы муниципаль районының Иске Казиле авыл җирлеге Уставының 26 статьясы нигезендә, 2025 нче елның 1 нче декабрендэ булып узган гражданнар жыены нәтиҗәләре нигезендә түбәндәге сорау буенча беркетмә төзелде: «Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Иске Казиле авыл җирлегенә кергән Иске Казиле торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән (көндезге формада белем алучы студентлардан, өлешчә мобилизацияләүдэ булган һәм аларның гаилә әгъзаларыннан тыш) 2026 елда 600 сум күләмендә үзара салым кертергэ.

2. Алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәгеләрне үтәү буенча юнәлтергә:

1) торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмиятле автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту;
2) торак пунктның башка территорияләрен төзекләндерү;
3) янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү;
4) тышкы яктырту урам челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны ремонтлау.

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә гражданнар җыенында катнашучы 121 кеше кертелгән, җыенда катнашучылар саны 66 кеше тавыш бирүдә катнашкан.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«Әйе» позициясе өчен гражданнар җыенында катнашучы 66 кеше тавыш бирде;

«Юк» позициясе өчен җыенда катнашучы 0 тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар итте**:**

1. Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Иске Казиле авыл җирлеге составына керүче Иске Казиле авылы халык җыенын узган дип таныргa, халык җыены нәтиҗәләрен дөрес дип санарга.

2. 2026 елда Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Иске Казиле авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән, көндезге формада укучы студентлар, олешчэ мобилизациядэ булганнар хэм аларнын гаилэ эгьзаларыннан тыш һәр балигъ булган кешедән 600 сум күләмендә үзара салым кертергә. Алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәгеләрне үтәү буенча юнәлтергә:

1) торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмиятле автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту;
2) торак пунктның башка территорияләрен төзекләндерү;
3) янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү;
4) тышкы яктырту урам челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны ремонтлау.

3. Әлеге карарны Иске Казиле авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә, Кама Тамагы муниципаль районының рәсми сайтында, хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (httr://pravo.tatarstan.ru), кабул ителгәннән соң 10 көн эчендә бастырып чыгарырга (https://kamskoye-ustye.tatarstan.ru/).

Халык җыенында рәислек итүче ,
Татарстан Республикасы Кама
Тамагы муниципаль районы
Иске Казиле авыл җирлеге башлыгы: И.Х.Сагьдиев